| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 564-25/э-2020

«Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2021 елга хосусый тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр 2021 елга календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, «Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2021 елга зарури тулай табышын (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 №564-25/э-2020
карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2021 | 148 633,68 | 174,95 | 0,50979 | 148 633,68 | 174,95 | 0,50979 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 564-25/э-2020
карарына 2 нче кушымта

«Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2021 елга зарури тулай табышы
(югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Зеленодольск индустриаль паркы» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2021 | 8318,72 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге